**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 30» марта 2020 ел № 2

2020 елда Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру тәртибен һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибен расларга.

2. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә 1 сентябрьгә кадәр Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитетына хисап елы өчен, хисап елына кадәрге ел өчен түбәндәге белешмәләрне җибәрергә тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланучы түләүчеләр саны турында;
- Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең һәр салым чыгымы буенча Шилнәбаш авыл җирлеге бюджетының төшеп калучы керемнәре суммасы турында.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет Җитәкчесе О.А. Гончарова

Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 30 марта 2 номерлы карарына кушымта

2020 елда Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнәбаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибе турында

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү кагыйдәләрен (алга таба – тәртип, муниципаль берәмлек) билгели.

2. Әлеге тәртиптә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр белән (алга таба - гомуми таләпләр) билгеләнгән терминнар һәм төшенчәләр кулланыла.

3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар, муниципаль программаларның структур элементлары һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

4. «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын бәяләү максатында, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзи;

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра.

## II. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан формалаштырыла һәм агымдагы елның 1 июненә кадәр раслана.

6. Муниципаль берәмлекнең расланган салым чыгымнары исемлеге муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

7. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатыннан, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитетына хисап финанс

елы һәм хисап чорына кадәрге ел өчен муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының фискаль характеристикалары турында мәгълүмат бирә.

8. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатында, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты ел саен 1 августка кадәр Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, муниципаль берәмлекнең тиешле салым чыгымнарын, шул исәптән хисап елында һәм алдагы хисап елында гамәлдә булган норматив хокукый актларын һәм әлеге тәртипкә кушымтада каралган башка мәгълүматны күрсәтеп, түләүчеләр категорияләре турында белешмәләр җибәрә.

9. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә кертелгән мәгълүматны үзгәртүне күздә тоткан норматив хокукый актлар кабул ителгән очракта, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты тиешле норматив хокукый акт үз көченә кергән көннән соң 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертә.

## III. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү тәртибе

10. Салым чыгымнарын бәяләү Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары күләмнәрен бәяләү;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү.

11. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгын бәяләү;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү.

12. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатчанлыгы критерийлары булып тора:

муниципаль берәмлек салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына, муниципаль программаларның структур элементларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе;

салым түләүчеләрнең ташламалардан файдаланучыларның саны һәм бишьеллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны белән чагыштыруы белән характерлана торган салым ташламаларына ихтыяҗы.

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсе генә булса да туры килмәгән очракта, Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитетына түләүчеләргә ташламаларны саклау (аныклау, юкка чыгару) турында тәкъдимнәр тапшырырга кирәк.

13. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының нәтиҗәлелек критерие буларак муниципаль программа максатларына яисә муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга керми торган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең ким дигәндә бер күрсәткече (индикаторы) яисә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары йогынты ясый торган башка күрсәткеч (индикатор)

билгеләнә. Әлеге күрсәткеч (күрсәткечләр) хисап елына, хисап елы алындагы елга, агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына билгеләнә.

муниципаль программа максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга кермәгән социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткече (индикаторы) дәрәҗәсен үзгәртүдә түләүчеләр өчен каралган ташламалар өлеше бәяләнергә тиеш, ул күрсәтелгән күрсәткеч (индикатор) зурлыгының ташламаларны исәпкә алып һәм күрсәтелгән күрсәткеч (индикатор) зурлыгының ташламаларны исәпкә алмыйча аермасы буларак исәпләнә.

14. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.

15. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү максатында, муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына кермәгән социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенә чагыштырмача анализ ясала.

16. Чагыштырма анализ муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану очрагында муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары күләмнәрен һәм бирелгән ташламалар күләмен (муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторының) артуы муниципаль берәмлек муниципаль программалары салым чыгымнарының 1 сумына һәм альтернатив механизмнар куллану очрагында шул ук күрсәткечкә (индикаторга) ирешү өчен муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының 1 сумына арту) үз эченә ала.

Муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнары сыйфатында исәпкә алынырга мөмкин:

а) субсидияләр яки муниципаль берәмлек бюджеты акчалары хисабына ташламалар алу хокукына ия түләүчеләргә турыдан-туры финанс ярдәменең башка формалары;

б) ташламаларга хокукы булган түләүчеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләр бирү;

в) ташламаларга хокуклы түләүчеләр эшчәнлеге өлкәсендә норматив җайга салуны һәм (яки) контроль-күзәтчелек функцияләрен гамәлгә ашыру тәртибен камилләштерү.

17. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү 1 октябрьгә кадәр башкарыла һәм үз эченә ала:

- салым чыгымнарын бәяләү өчен күрсәткечләр исемлеге буенча мәгълүматны;

- салым чыгымнарының максатчан характеристикаларына ирешү (ирешмәү) турында, муниципаль программа максатларына һәм (яки) социаль-икътисадый сәясәт юнәлешләренә (максатларына) ирешүгә салым чыгымының өлеше турында нәтиҗәләр тупланган язма аңлатманы;

- аларга ирешү өчен нәтиҗәлерәк альтернатив механизмнар булу (булмау) турында тәкъдимнәрне;

- салым чыгымнарын саклау, аныклау (юк итү), яңа салым чыгымнарын билгеләү буенча тәкъдимнәрне.

18. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Кушымта

Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү өчен күрсәткечләр исемлеге

| Күрсәткеч исеме | |
|---|---|
| I. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының норматив һәм максатчан характеристикалары | |
| 1. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты |
| 2. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары |
| 3. | Салым ташламалары, азат ителү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе |
| 4. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы |
| 5. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат ителүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлгә керү датасы |
| 6. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләрнең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры |
| 7. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән салым ташламаларының, азат ителүләрнең һәм башка преференцияләрнең гамәлдән чыгу датасы |
| 8. | Салым ташламаларының, азат ителүләрнең һәм салымнар буенча башка преференцияләрнең исеме |
| 9. | Салым чыгымының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) |
| 10. | Салым түләүчеләргә муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары |
| 11. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән салым ташламалары, азат ителүләр һәм башка преференцияләр каралган салым исемнәре |
| 12. | Түләүчеләрнең аерым категорияләренә бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләрнең һәм башка преференцияләрнең башка түләүчеләр белән чагыштырганда өстенлекләре үзенчәлекләрен билгели торган төре |
| 13. | Салым ташламалары, азат ителүләр һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирелә торган салым ставкасы күләме |

| | |
|---|---|
| 14. | Салым ташламалары, азат ителүләр һәм салымнар буенча башка преференцияләр бирү белән бәйле рәвештә, муниципаль программалар максатларына һәм (яки) дәүләт программаларына карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатлары ирешү күрсәткече (индикаторы) |
| II. Салым чыгымының фискаль характеристикалары | |
| 15. | Хисап елы өчен һәм хисап елына кадәр булган ел өчен муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары нигезендә салым түләүчеләргә бирелгән салым ташламалары, азат ителүләр һәм башка преференцияләр күләме (мең сум) |
| 16. | Агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат ителүләр һәм башка преференцияләр күләмен бәяләү (мең сум) |
| 17. | Муниципаль берәмлекнең хокукый актларында билгеләнгән салым ташламасыннан, азат ителүдән һәм башка преференциядән (берәмлекләрдән) файдаланган салым түләүчеләр саны |
| 18. | Салым чыгымының нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре |